МЭР
ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕ ХАКИМЕ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ г. Иннополис № ________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең XXIX гражданнары җыенын чакыру турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнар җыены Регламенты җитәкчелегендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәге мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының XXIX җыенын чакырырга:

1.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» XXV гражданнар җыенының 2017 елның 19 декабрендәге 6 номерлы «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында.

1.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының XXVIII җыены «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгын, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләү, гарантияләр, премияләү, матди ярдәм түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында»19.04.2018 ел, №5 карарына үзгәрешләр кертү турында.

1.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында.

1.4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында.

1.5. Төрлеләр.

2. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең гражданнар җыенын үткәрү датасын һәм вакытын - 2018 елның 31 маенда 14 сәг. 00 мин. билгеләргә.

3. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнары җыенын үткәрү урынын - Россия, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, Квант бульвар ур., 3 йорт («Лицей Иннополис» ДАМУ бинасы).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче

Р. Р. Шагалиев